**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«26» апрель 2019 ел №2/5

**2018 ел өчен Кече Шилнә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең «2018 ел өчен Кече Шилнә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2018 ел өчен Тукай муниципаль районы районы Кече Шилнә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 23923,17 мең сум, чыгымнар буенча 31781,23 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- 2018 ел өчен Кече Шилнә авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1 кушымта нигезендә.
- 2018 ел өчен Кече Шилнә авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.
- 2018 ел өчен Кече Шилнә авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 кушымта нигезендә.
- 2018 ел өчен Кече Шилнә авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан статьялар һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүнең функциональ структурасы буенча әлеге карарга 4 кушымта нигезендә.
- 2018 ел өчен Кече Шилнә авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе А.Г.Даутов